ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.06.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1792**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 1766 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 284-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 1766 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.8.2.1 пунктындагы 6 пунктчасына «линия объектлары булган инженерлык корылмаларын капиталь ремонтлау максатларында, шулай ук мондый инженерлык корылмаларын (өлешләрен) капиталь ремонтлау максатларында гавами сервитут билгеләү очрагыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.2. Административ регламентның 2.7.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга:

«9) гаризада һәм аңа кушылып бирелгән документларда каршылыклы белешмәләр булу».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин